Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәре җаваплары
2017-2018 уку елы
11 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 120 минут.
Максималь балл – 64.

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. ***Маэмай*** сүзендәге тартык һәм сузык авазлар саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) 2 тартык, 4 сузык

ә) 3 тартык, 3 сузык

б) 2 тартык, 3 сузык

в) 4 тартык, 2 сузык

2. Фразеологизм кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Фәрит елга буенда балык тота иде. (Ә.Кари)

ә) Көзге көн бала кебек: әле елый, әле көлә. (Мәкаль)

б) Аның бәгырен корт кимерә иде. (Ф.Латыйфи)

в) Ат – чабышта, кеше эштә беленә. (Мәкаль)

3. Җөмләдәге ясалма сүзләрнең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Ачык тәрәзәдән апаның кояш кебек түм-түгәрәк ипиләрне кызыл ашъяулыкка куеп бүлгәләве күренә. (Ш.Маннапов)

а) бер

ә) ике

б) өч

в) дүрт

4. Җөмләләрдәге фигыльләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Тәвә кошлары очмый, ләкин бик яхшы йөгерәләр. Чүлдә аларны ат белән куып җитү дә җиңел түгел. (Вакытлы матбугаттан)

а) очмый, йөгерәләр, җитү

ә) очмый, йөгерәләр, куып

б) очмый, йөгерәләр, куып, җитү, җиңел түгел

в) очмый, йөгерәләр, куып, җитү

5. Җөмләдәге кисәкчәләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Тып-тын, тик умывальник борыныннан чутылдап тамчы тамгалый да келт-келт сәгать йөри. (Р.Төхфәтуллин)

а) тып- ә) тып-, да б) тик в) да

6. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Аларга бүген өйдә **грамматикадан** боерык фигыльле өч җөмлә язып килергә куштылар.* (Г.Тавлин)

а) урын хәле

ә) туры тәмамлык

б) кыек тәмамлык

в) рәвеш хәле

7. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли торган чара дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Сез күрдегезме җирдә дә бер йолдыз кабынганны? (Ф.Бәйрәмова)

а) көттерү интонациясе

ә) *җирдә* бәйлек сүзе

б) мөнәсәбәтле сүз

в) *-ны* кушымчасы

8. Җөмлә төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Язлар вәгъдә иткән җылылыкны,

Җәйләр үткәч, көзләр китерде. (К.Булатова)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

б) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

в) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

II. Теоретик бирем.

Хат стиле турында белгәннәрегезне языгыз. ***(10 балл)***

III. Гамәли һәм иҗади бирем.

Уйламыйча, дустым бер сүз әйтте,

ул сүз йөрәгемә кадалды.

Үзе берни белми китеп барды,

ә сүз калды. (И.Юзеев)

1. *Калды* сүзенә фонетик анализ ясагыз. ***(3 балл)***

2. *Кадалды* сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. ***(3 балл)***

3. *Уйламыйча* сүзенә морфологик анализ ясагыз. ***(3 балл)***

4. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез. ***(16 балл)***

5. Икенче җөмләнең схемасын сызыгыз, билгеләмә бирегез. ***(3 балл)***

6. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(10 балл)***